КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 17 октябрь г.Казань № 937

Татарстан Республикасы территориясендә аеруча куркыныч хайваннар чирләре учакларын бетергәндә хайваннарны алуны оештыру һәм үткәрү турында

«Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Аеруча куркыныч хайваннар чирләре учакларын бетергәндә хайваннарны һәм терлекчелек продуктларын алу турында» 2006 елның 26 маендагы 310 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының « Татарстан Республикасы территориясендә хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганаклары барлыкка килүне булдырмау һәм аларны бетерү максатларында хайваннарны алуны һәм терлекчелек продуктларын алуны оештыру һәм үткәрү тәртибен, хайваннарны алу һәм терлекчелек продуктларын алу нәтиҗәсендә гражданнарга һәм юридик затларга килгән зыянны каплау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хайваннардан эшләнгән продуктлар һәм чималны эшкәртү һәм саклау предприятиеләрендә дәүләт ветеринария күзәтчелеге турында нигезләмәне һәм хайваннарның аеруча куркыныч авыруларында хайваннарны һәм терлекчелек продукциясен алу тәртибе хакында аңлатманы раслау турында» 2002 ел, 29 гыйнвар, 38 нче карарына үзгәреш кертү хакында" 2018 ел, 14 февраль, 84 нче карары нигезендә, Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең «Аеруча куркыныч хайваннар чирләре учакларын бетергәндә хайваннарны алу үткәрү кирәклеге турында" 2020 елның 14 октябрендәге 4708-исх номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендә кош гриппы чыганакларының барлыкка килүен булдырмау һәм бетерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Буа районының аерым территориясендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләү һәм аның таралу куркынычы янау белән бәйле рәвештә, аның иминлексезлеге

сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында» 2020 елның 13 октябрендәге ПУ-686 номерлы Указының 1 пункты белән билгеләнгән территориядә хайваннарны алырга.

2. Карарга теркәлгән Хайваннарны алу үткәрү буенча махсус комиссия составын расларга.

3. Хайваннарны алу үткәрү буенча махсус комиссия әлеге карарның 1 пунктында каралган чараларны билгеләнгән тәртиптә башкаруны оештырырга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 17 октябрь, 937 нче
карары белән расланды

Хайваннарны алу үткәрү буенча махсус комиссия составы

| | |
|---|---|
| Мотыйгуллин Габделхак Госман улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары, махсус комиссия рәисе |
| Иванов Евгений Николаевич | Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы буенча Баш дәүләт ветеринария инспекторы, махсус комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Әхмәтов Камил Равил улы | «Буа район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе башлыгы |
| Гатин Идрис Мөдәрис улы | Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең дәүләт ветеринария күзәтчелеге бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Гыйззәтов Илдус Гашыйк улы | Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары (килешү буенча) |
| Ильина Елена Ивановна | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары вазыйфаларын башкаручы |
| Сафин Фиргать Мәсгут улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенең Апас территориаль бүлеге башлыгы. |

___